СОВЕТ СТАРОМАТВЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МАТВЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17.10.2022 ел** **№ 12**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге составына керүче Иске Александровка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 17.10.2022 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:«Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме,түбәндәгеләрдән тыш: *көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзалары, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары* һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү:

1.Иске Александровка бистәсендә су башнясын ремонтлау (басым датчигын сатып алу һәм урнаштыру, ремонт өчен материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 45 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 28 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 28 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:
1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Александровка торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 2023 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа түбәндәгеләр керми: *көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I торкем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итучеләр, аларның гаилә әгъзалары, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары* һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү:

- Иске Александровка торак пунктында су башнясын ремонтлау (басым датчигы сатып алу һәм урнаштыру, ремонт өчен материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

2. Иске Матвеевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен халыкка игълан итү http://menzelinsk.tatarstan.ruТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo tatarstan урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Д.Г. Шакиров
(имза) (имзаны кишәйтү)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Советы Д.Г. Шакиров
(имза) (имзаны кишәйтү)

ОГРН 1021605552913
Совет Староматвеевского сельского поселения
ИНН 1628002820